СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

28.11.2024 с. Шеланга 42-238

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге территориясендә турист салымы кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлегенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге территориясендә 2025 елның 1 гыйнварыннан турист салымын кертергә.

2. Турист салымы ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2025 елда салым базасының 1 проценты күләмендә,
- 2026 елда салым базасының 2 проценты күләмендә,
- 2027 елда салым базасының 3 проценты күләмендә,
- 2028 елда салым базасының 4 проценты күләмендә,
- 2029 елдан башлап салым базасының 5 проценты күләмендә.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров